БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 07 2026 ел № 229

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы» Татарстан Республикасы Законына туры китереп һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 4 октябрендәге 275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 нчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17 статья буенча — Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының эйдәп баручы белгече;».

1.2. 16 нчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6 статья буенча – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының әйдәп баручы белгече;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов